| | |
|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.12.2023 г. Казань № 410-14/т-2023

Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә даими пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга 2024 елга чик дәрәҗәдә максималь тарифлар билгеләү турында

«Автомобиль транспорты һәм җир өсте шәһәр электр транспорты уставы» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары, «Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 7 июнендәге 7-1/т номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими маршрутларда автомобиль транспорты һәм җир өсте шәһәр электр транспорты белән даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуга җайга салына торган тарифлар билгеләү тәртибе, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 2023 елның 12 декабрендәге 53-ПР номерлы беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасы нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә даими пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча автомобиль

транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүгә чик дәрәҗәдә максималь тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән максималь дәрәҗәдә чик тарифлар 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
08.12.2023 № 410-14/т-2023
номерлы карарына кушымта

# Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә пассажирлар йөртүнең даими муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар

| Транспорт төре | Бер тапкыр бару һәм бер урынлы багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар (сум) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Бер тапкыр бирелә торган билет сатып алганда | | юлга озак файдаланудагы билет белән түләгәндә (транспорт картасы) | |
| | акчалата исәп-хисап | акчасыз исәп-хисап[1] | 1 тапкыр бару[2] | 100 һәм аннан күбрәк мәртәбә барган өчен[3] |
| Автобус | 42 | 38 | 38 | 28 |
| Троллейбус | 42 | 38 | 38 | 28 |
| Трамвай | 42 | 38 | 38 | 28 |

<1> түләү (банк) карталары (транспорт кушымтасыннан башка) яки бәйләнешсез түләү технологиясе булган башка электрон түләү чаралары ярдәмендә;

<2> юлда билгеле бер сумма чикләрендә бару һәм транспорт кушымтасы булган банк карталары белән түләү хокукын бирүче, озак файдаланыла торган билетлар ярдәмендә түләгәндә;

<3> күрсәтелгән вакыт эчендә юл өчен саны билгеләнгәнчә бару хокукын бирә торган озак файдаланудагы билетлар белән түләгәндә.

Искәрмә. Багаж алып бару бәясе юл йөрү бәясеннән аерым түләнә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге